Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите

№1 Сентябрь, 2020 ел

# Нурчыклар

## *ИГЪТИБАР! БАКЧАДА БЕРЕНЧЕ ГАЗЕТА!!!*

Бакчабызның үз газетасын булдыру теләге күптән бар иде. Ниһаять хыялыбыз тормышка ашты. Газетабыз бакчабызда узган бәйрәмнәребезне, балалар тормышындагы кызыклы вакыйгаларны үз эченә ала. Әти-әниләр, педагоглар үзләренә файдалы киңәшләр, ә балалар башваткычлар, кызыклы ребуслар таба, күңелле сәхифә битендә һәркем үзенең иҗат җимешен күрә ала. Газетабыз өчен “Нурчыклар” исеме барыбызның да күңеленә хуш килде. Газетаны айга бер тапкыр системалы рәвештә бастырырга уйлыйбыз. Газетаның электрон варианты белән сайтта танышырга мөмкин. Хәерле сәгатьтә!

## Бүгенге санда

1. Белем көне
2. “Ел тәрбиячесе -2020”
3. Бакчабызда “Самокат көне”
4. Юл йөрү кагыйдәләре
5. Төрлесеннән



### *Хөрмәтле тәрбиячеләр, хезмәткәрләр һәм ветераннарыбыз!*

Сезне чын күңелемнән һөнәри бәйрәмегез - Тәрбиячеләр һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре көне белән тәбрик итәм!

Сезнең һөнәр –гаять мөһим һәм җаваплы. Бәхетле балачак һәр сабыйның киләчәк тормышы аны кечкенәдән тәрбия кылучының зирәклеге, сабырлыгы һәм игътибарына бәйле. Һәр баланың күңел дөньясын аңлап, йөрәгенә ачкыч таба белү зур тырышлык һәм эчке тоемлау таләп итә.

Тәрбияләнүче балаларда мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык, хезмәт сөючәнлек, максатчанлык хисләре тәрбияләвегез, аларның иҗади сәләтләрен күрә һәм үстерә белүегез күңелләрдә соклану һәм хөрмәт хисе уята.

Һөнәри осталыгыгыз, күңел сафлыгыгыз, сабырлыгыгыз, балаларга күрсәткән кайгыртучан һәм җылы мөгамәләгез өчен бик зур рәхмәт сезгә! Киләчәктә дә зур уңышлар, мәңге сүнмәс иҗат, балалар мәхәббәте юлдаш булсын! Сезгә һәм гаиләләрегезгә бәхет, шатлык, сәламәтлек, иминлек телим!

*Иң изге теләкләр белән Э.З.Абүзәрова*



## “Игътибар балалар!”

3 сентябрь көнне "Кояшкай" балалар бакчасында "Игътибар балалар" программасы кысаларында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын пропагандалау буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече Санатуллина Э.И. булып китте.

Әлеге чара кысаларында балалар юл хәрәкәте кагыйдәләрен тагын бер кат искә төшерделәр, моның өчен алар юл йөрү юлы аша чыкканда, балаларны автомобиль салонында йөрткәндә һәм велосипед белән идарә иткәндә куркынычсызлык кагыйдәләре турында белергә генә түгел, ә үтәргә кирәклеген аңладылар. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга юл йөрү кагыйдәләрен белү өчен мультфильмнар карау оештырылды.

Чараның нәтиҗәсе балалар өчен онытылмаслык сюрприз булды. Һәр бала бүләккә яктылык чагылдыра торган брелок, шулай ук юл билгеләре комплекты, "юл билгеләре" темасына пазллар җыелмасы алдылар.

***Юлларда игътибарлы булыйк! Юлларда имин йөрик!***

## “Белем көне”



Җәйге ялдан соң балалар үсеп, ял итеп балалар бакчасына килделәр.

Бу көнне балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр өчен педагоглар чын бәйрәм оештырдылар. Иртә таңнан музыка яңгырады. Балалар бакчасы территориясе флаглар һәм шарлар белән бизәлгән иде. Болар барысы да бәйрәм атмосферасы тудырды.

Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрне Белем көне белән котларга әкият персонажлары килде. Әкият геройлары балалар белән кызыклы уеннар уйнадылар, биеделәр, табышмаклар чиштеләр. Уку елы күңелле башланып китте. Балаларда бик күп уңай эмоцияләр һәм тәэсирләр алды.

***Редколлегия исеменнән быелгы елның уңышлы үтүен теләп калабыз!!!***





## Бөтенроссия “ Ел тәрбиячесе -2020" һөнәри конкурсының муниципаль этабы

Без коллегабыз Собина Марина Александровнаны лаеклы бүләк - Бөтенроссия “ Ел тәрбиячесе -2020" һөнәри конкурсының муниципаль этабы призеры дипломы белән котлыйбыз. Аңа алга таба да зур уңышлар, уй-ниятләренең тормышка ашуын телибез.



"Уголок России, С детства дорогой. Нет тебя красивей, Татарстан родной" дип аталган региональ шигырь уку конкурсында "Кояшкай" балалар бакчасының зурлар төркеме балалары 1 һәм 2 дәрәҗә лауреат һәм дипломант,2 нче зурлар төркемдә тәрбияләнүче Долгова Полина, мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче Газизуллина Әминә - 1 нче дәрәҗә лауреат булдылар.

***Котлыйбыз!!!***

# Балалар белән уйнар өчен төрле-төрле уеннар





**Песием, песием**

Бер бала икенче балага кул сыртын сузып тора. Икенчесе, аның кул сыртын сыйпый-сыйпый, түбәндәгечә тиз-тиз такмак әйтә:

*Песи, песи, пес итәр,*
*Ана песи сөт эчәр,*
*Ана песи сөт эчкәндә,*
*Ата песи күз кысар.*
*Ал дигәндә алмасаң,*
*Лап итәр дә шап итәр!*

«Лап итәр» дигәндә, сыйпаганы теге баланың кул сыртына шап иттереп суга. Тегесе кулын тартып алып өлгермәсә, отылган була. Отылмаса, тегесе сыйпаучы, монысы сугучы була.
Искәрмә: 2-3 яшьлек балалар да бу уенны яратып уйный.

## Түбәтәй

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый түбәтәйне бер-берсенә бирәләр . Җыр ахырында түбәтәй кемдә булып кала, шуңа «җәза» бирелә (бии, җырлый, шигырь сөйли, этәч булып кычкыра һ. б.) Уен шулай дәвам итә.



*Түбәтәеңне кигәнсең,*
*Бик еракалардан килгәнсең,*
*Төскә матурлыгың белән*
*Шаккатырыйм,— дигәнсең.*


*Түп-түп-түбәтәй,*
*Түбәтәең укалы.*
*Чиккән матур түбәтәең*
*Менә кемдә тукталды.*

## Ватык телефон



Балалар бер рәткә тезелеп утыралар. Бер бала уенны алып баручы була. Ул иң беренче утырган баланың колагына тиз генә бер сүз әйтә. Анысы үз чиратында янындагы иптәшенә, ә ул — күршесенә… Шулай итеп, бу сүз, колактан-колакка әйтелеп, теземнең икенче башына барып җитә. Шуннан соң уенны алып баручы сүз барып тукталган соңгы баладан:«Нинди сүз?» — дип сорый. Тегесе әйтә. Әгәр сүз дөрес барып җитмәсә, ул рәт буенча сүзнең кемдә «бозылганлыгын» эзләп китә. Сүзне бозган бала артка барып утыра, һәм уен яңадан башлана. Әгәр сүз дөрес килеп җитсә, уенны алып баручы үзе артка барып утыра. Аның алдындагы бала уенны алып баручы була.

## Кечкенә туплар



Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларда утырып торалар. Рәттән утырган 2 балага тәрбияче берәр кечкенә туп бирә. Бер бала тупны уң якка, икенчесе сул якка җибәрә (балалар тупларны бер-берләренә бирәләр). Ике туп «очрашкач», туплы балалар икесе ике якка йөгереп китәләр. Калган балалар бу вакытта «йөгердек, йөгердек» дип кабатлыйлар, кулларын чәбәклиләр. Ике бала, кара-каршы очрашкач, тупларын тәрбиячегә тапшыралар. Ул аларны башка балаларга бирә һәм уен дәвам итә.

## Такыя үрәм

Балалар түгәрәк ясап баса, алып баручы уртада кала. Алып баручы: Мин йөримен болында, Чәчәкләр бик күп монда. Чәчәкләр җыям, Такыя үрәм. Алдан балаларның һәрберсенә чәчәк исеме кушылган була. Алып баручы: Кыңгырау чәчәк, кил әле, Бер елмаеп көл әле, Кочагыма кер әле. «Кыңгырау чәчәк» уртага чыга. Алып баручы белән «кыңгырау чәчәк» икесе ике якка йөгереп китә, буш урынны алырга тырышалар. Кем урынсыз кала, шул уенны дәвам итә.

# Кроссворд






В выделенных клетках: Как называется праздник хлеборобов?

По горизонтали:

1. Птица соловей на татарском языке.
2. Леший из сказки Г.Тукая.
3. Дедушка на татарском языке.
4. Женский татарский головной убор.
5. Место, где обитают звери и лешие.
6. Известное стихотворение Г.Тукая: "И туган...".
7. Главное национальное блюдо татар.
8. Мужской татарский головной убор.

## Элементы национального татарского костюма




«Нурчыклар» гәҗитен
гамәлгә куючы:
Татарстан Республикасы
Буа шәһәренең катнаш
төрдәге “Кояшкай” балалар
бакчасы” муниципаль бюджет
учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гиниятуллина Д.Р.
Шакирова Г.Р.

Безнең адрес:
422430, Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru